УДК 371.2

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАРЛАРНЫҢ ТӨРКЕСТАНДА ҺӘМ КАЗАХ ДАЛАЛАРЫНДА МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Л.Р. Мортазина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*lyalyamur@mail.ru*

Мәкаләдә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарларның Төркестанда һәм Казах далаларында кардәш халыкларга аң-белем таратудагы эшчәнлеге яктыртыла. Татарларның мөселман гадәтләрен һәм йолаларын тарату, төрки халыкларны руслаштыру сәясәтеннән саклауга керткән өлешләре, әлеге мәсьәләгә карата хөкүмәтнең гамәлләре тасвирлана. Татар мәгърифәтчеләренең кардәш халыклар өчен мәктәпләр ачу, белем бирү, укытуны методик яктан тәэмин итү, милли кадрлар әзерләү һәм милли мәктәпләр төзүгә керткән өлешләре күрсәтелә.

**Төп төшенчәләр:** Төркестан, мәгърифәт, мәгариф, кардәш телләр, татар педагоглары, мәдрәсә, рус – җирле халык мәктәбе, җәдит мәктәбе, кызлар мәктәбе, яңа ысул, дәреслек, әлифба

Татарларның башка төрки халыклар белән үзара бәйләнеше күп гасырларга сузылган. Бик якын булган кардәш телләр, дин уртаклыгына нигезләнгән бу мөнәсәбәтләр икътисади, мәдәни, мәгариф өлкәләрендә шактый киң чагылыш таба. XVIII гасырның икенче яртысында татарларда дини белем бирү системасының яңадан торгызылуында Дагыстан моделенең роле зур булса, соңрак, татарларның Урта Азия белән сәүдә бәйләнешләре ныгу белән, Бохара, Сәмәрканд, Хива мәдрәсәләре төп һәм иң дәрәҗәле уку йортларына әверелә. Бирдә белем алган белгечләр, ватаннарына кайтканнан соң, Урта Азия уку йортлары үрнәгендә ислам теологиясен укытуга нигезләнгән мәдрәсәләр ачалар. Шул рәвешле XIX гасыр башларында Россиянең эчке губерналарында Урта Азия белем бирү системасы ныгып урнаша [32, б.94]. XIX гасыр урталарыннан, бигрәк тә аның соңгы чирегендә, Төркестан һәм Казах далаларында мәгърифәт, аң-белем таратуда, киресенчә, татарларның роле арта.

Татар халкының башка милләтләрне үстерүгә, аларны агартуга керткән өлешләре тикшеренүчеләр тарафыннан озак вакытлар буена игътибарга алынмады. Совет идеологиясе хакимлек иткән чорда бу мәсьәлә бары тик бер генә күзлектән – Совет хөкүмәте һәм Коммунистлар партиясенең казанышлары буларак кына өйрәнелде һәм шулай тәкъдим ителде дә [28]. Ә революциягә кадәрге чорда төрле милләтләрнең мәгарифен үстерүдә бары тик рус мәгърифәтчеләренең эшчәнлегенә генә басым ясалды. Мәгариф тарихы һәм педагогик фикер үсешенең иң мөһим һәм тулы чагылышы булырга тиешле педагогик фикер антологияләрендә (1980 елларда СССРның аерым республикалары халыкларына багышланган мондый басмалар шактый дөнья күрде), кызганыч, бу фикер берничек тә чагылыш тапмады [21, б.216–217]. Шулай да ХХ гасырның беренче чирегендә дөнья күргән хезмәтләрдә, аерым алганда Н.А. Бобровников, В.В. Бартольдт тикшеренүләрендә, татарларның Төркестан халыкларының мәгарифен үстерүдә башкарган аерым эшләре ассызыклана [7; 8; 11]. Икенче бер автор, М.П. Павлович исә, татарларның революциягә кадәр башка төрки халыкларны агартудагы ролен ассызыклап: «Татарлар Көнчыгышка – Башкортстанга, Кыргызстанга, Төркестанга иң беренче башлап мәгърифәт утын (факелын) алып килделәр», – дип язды [24, б.6–7]. XX гасыр ахырында, бигрәк тә XXI гасыр башында, татарларның Төркестан халыкларының мәдәни, мәгариф үсешендәге урынын чагылдырган хезмәтләр күренә башлады [9; 16; 23; 29].

Билгеле булганча, Төркестанга һәм Казах җирләренә татарлар шактый элек килеп урнашалар. Чукындыру сәясәтеннән качып, ул якларга барып ирешкән татарлар, мөгаен, иң зур өлешне тәшкил итәдер. Шулай ук Екатерина II заманында да татарлар бу җирләргә күпләп килә – патшабикә милләттәшләребезне күчмә халыкларны «агарту» максатында файдалана [38, б.32]. Татарлар, телләренең шунда яшәүче башка төрки халыкларның телләре белән генеалогик яктан охшаш булуы сәбәпле, аларны бик тиз арада үзләштергәннәр. Уртак дин шулай ук зур әһәмияткә ия булган. Рус телен белү исә татарларга Россия хөкүмәте белән башка төрки телле дәүләтләр арасында арадашчылык ролен үтәү мөмкинлеген биргән: татарлар бик еш кына тылмач хезмәтен үтәгәннәр, сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга салуда булышлык иткәннәр.

Мисал өчен, кыргызлар тарафыннан Россиягә язылган беренче хатның авторы татар кешесе, Казан сәүдәгәре Габдрахман Нурмәмәтовның приказчигы Мөслим Агафуров була. 1787 елда Көнбатыш Себер хакимнәреннән кыргыз хакиме Атак-батырга аның тарафыннан китерелгән хат тантаналы рәвештә Россия дәүләте вәкиленнән китерелгән рәсми хат буларак кабул ителә [26, б.19].

Төркестан халыкларының мәдәни үсешен өйрәнгән галим В.В. Бартольд 1814 елда руслар белән кыргызлар арасында сәүдә эшләрен көйләүдә арадашчы булган Казан татары Фәйзулла Сәйфуллин турында яза [7, б.30]. Моннан тыш, ул Россия ягыннан дәүләти эшләр буенча рәсми

вәкил ролен дә үтәгән [26, б.18]. Ф. Сәйфуллинның әлеге эшчәнлегенә зур бәя биреп, кыргызлар хәтта аны бүләкләүне сорап Омск өлкәсе башлыгына махсус хат та юллаганнар [26, б.33]. Бу максаттан татарларны Урта Азиядә яшәгән башка халыкларның мәнфәгатьләрен үтәү өчен дә файдаланганнар. Тарихи чыганаклар татарларның әлеге җирләргә тукыма, тире һәм күн белән сәүдә итү өчен килүләре, кайберләренең шунда төпләнеп калуларын раслый. Шулай итеп, Төркестанга нигездә сәүдә белән шөгыльләнгән, аннан керем алган хәлле һәм укымышлы кешеләр килгән [2, б.13]. XVIII–XIX гасырлар чигендә Ташкент шәһәре тирәсендә барлыкка килгән беренче татар авылы Нугай-курган 200 хуҗалыктан торган, һәм, шунысы кызык, бу әлеге тирәләрдә бәрәңге үстергән бердәнбер торак урын була [25, б.98]. XIX гасыр ахырында татарлар шулай ук Семипалатинск, Уральск, Кызылъяр (Петропавловск) һ. б. шәһәрләрнең шактый зур өлешен биләгәннәр.

Шулай итеп, үзләре дә кайчандыр Бохара, Хива мәдрәсәләрендә белем алган, XIX гасырда Россия һәм Европа мәдәнияте белән якыннан танышкан, белем бирү системасына үзгәрешләр кертү кирәклеген яхшы аңлаган татарлар Төркестанда һәм Казах далаларында кардәш халыкларны агарту эшенә керешәләр. Далада мөселман гадәтләрен һәм йолаларын таратучылар да татарлар була. Нәкъ менә шуның өчен дә Төркестанның генерал-губернаторы К.П. фон Кауфман татар мөселман руханиларына катгый рәвештә тискәре фикердә булган, ул аларда беренче чиратта дала миссионерларын күргән [8, б.136]. Татар муллаларының казах халкы тормышында авыр вакытларда аларны ассимиляциядән яклап, ата-бабалар динен саклап калуда зур эш башкаруларын Казахстан галимнәре дә таный [16, б.111; 3, б.5].

Билгеле булганча, Төркестан һәм Казах далаларындагы муллаларның күпчелеге татар милләтеннән була. Галимнәр раславынча, казах җирләре Россиягә кушылганчы, казахлар бары тик татар телендә генә укый-яза белгән [38, б.41]. Хәтта Н.И. Ильминский булышлыгы белән казах мәгърифәтчесе И. Алтынсарин тарафыннан ачылган казах мәктәбендә укытучыларның да күпчелеге татарлар булган [38, б.43].

Җәдитчелек агымы барлыкка килү белән, мәгърифәтчелек яңа баскычка күтәрелә. Җәдитчелек хәрәкәтенең бу төбәкләргә үтеп керүе, кайбер галимнәрнең 1905–1906 еллар белән бәйләвенә карамастан [11, б.80], иртәрәк чорда башланган дип карарга җирлек бар. В.В. Бартольд исәпләүләре буенча, Төркестанда җәдит мәктәпләре 1898–1899 елларда барлыкка килгән [8, б.136]. Кайбер фактлар моңарчы эшләп килгән мәдрәсәләрнең яңа ысул белән укытуга күчүләренең моннан да алданрак булуын раслыйлар[1]. Мәсәлән, «Тәрҗеман» газетасы 1893 елда Сәмәркандта Гани бай Хөсәеновның матди ярдәме белән сынау өчен (экспери-

[1] Мәсәлән, Т. Әйди 1890 еллардан соң ачылган җәдит мәктәпләрендә үзбәк балаларына белем биргән Ш. Мохтар, З. Габделваһап кебек татар мөгаллимнәрен искә ала [5, б.400].

менталь) җәдит мәктәбе оештырылу, анда укучыларның укырга-язарга өйрәнүдә уңышлары шактый югары булуы турында яза [31].

Яңа ысул белән укыта торган уку йортлары барлыкка килү якынча XIX гасырның 80 елларыннан бирле эшләп килгән рус – җирле халык мәктәпләренең («русско-туземная школа») эшчәнлегенә сизелерлек тәэсир итә, чөнки бу ике төр уку йортының укыту алымнары беркадәр охшаш була: икесе дә мөселманнарга европача белем бирүне, дөньяви фәннәрне, шул исәптән рус телен, укытуны максат итә. Мәсәлән, 1873 елда Ташкент шәһәрендә ачылган татар мәктәбе 1895 елда җәдитчә укытуга күчә, күп тә үтми, ул формасы белән дә, эчтәлеге белән дә Европа мәктәпләрен хәтерләтә башлый; анда рус сөйләменә өйрәтүгә зур игътибар бирелә [8, б.130].

Татарлар күбрәк яшәгән кайбер урыннарда рус – җирле халык мәктәпләре яңа барлыкка килгән дөньяви мәктәпләр күләгәсендә калырга мәҗбүр булалар. Гәрчә икесендә дә татар мөгаллимнәре (муллалары) белем бирсә дә, укыту нигездә татар телендә алып барылса да [38, б.34], күпчелек халык җәдит мәктәпләренә яки өйгә килеп укыткан татар мөгаллимнәренә өстенлек биргән. Мисал өчен, 1913 елда Кызылъяр шәһәре тирәсендәге волостьларда 1913 елда бары тик бер генә рус-кыргыз (рус-казах. – *Л.М.*) мәктәбе ачыла, анда да балалар саны аз була, чөнки күпләр балаларын татарларга биреп укыта. Хәтта, ара ераклыгына карамастан, ата-аналарның Кызылъярга барып, балаларын шундагы татар мәктәпләренә бирү очраклары да булган [27, б.96]. Шуны да искәртеп китү мөһим: бу елларда Кызылъярда татарлар, казахлар белән чыгыштырганда, күпчелекне тәшкил иткән.

Халык рус – җирле халык мәктәпләренә генә түгел, православие дине руханиларына юл ачып, үз бусагасына муллаларны якын китермәгән рус училищеларына да саклык белән карый. Шуңа күрә дә рус – җирле халык мәктәпләрен ачканда, мөселман мәгариф системасының шәригать кануннарын мәктәптә өйрәтү традициясен истә тотып, «анда җирле халыкка үз диннәрен үз муллалары өйрәтү» [8, б.130] мәҗбүрилеге шарт итеп куела. Ләкин күп очракта бу кагыйдә тормышка ашмаган, чөнки, муллалар аз булу сәбәпле, һәр мәктәп өчен аерым рухани билгеләү мөмкин булмаган. Татар мәдрәсәсе, билгеле булганча, әлеге шартны тулысынча үти алган.

Татар мәктәпләре иң беренче чиратта шәһәрләрдә ачыла. Рус – җирле халык мәктәпләре белән чагыштырганда, аларның саны бермә-бер күп була. Мәсәлән, 1910 елда Ташкентта 8 рус – җирле халык мәктәбе булса, яңа ысуллы мәктәпләрнең саны ике тапкыр күбрәк була [8, б.137]. 1910 елга Кокандта мондый мәктәпләр 16, Ташкентта – 20 була, шундый ук мәктәпләр Колҗага кадәр булган башка җирләрдә дә җитәрлек була [11, б.66]. Каракалпаклар өчен беренче җәдит мәктәбе татарлар тарафыннан 1907 елда Петроалександровск шәһәрендә ачыла. Озакламый дөньяви мәктәпләр Хуҗайлы һәм Конгырадта да барлыкка килә [34]. 1915 елда каракалпаклар өчен мәктәп оештыру өчен Казах далаларыннан биш татар чакырылуы, алар арасында Иманкулов атлы кеше дә булуы билгеле [15, б.114].

1917 елга каракалпак телендә «тоте окыу» дип аталган җәдит мәктәпләренең саны инде шактый була [15, б.114]. Гомумән алганда, Төркестанда 1910 елга җәдит мәктәпләренең саны 89 га җитә (кадим мәдрәсәләрен дә исәпләгән очракта, 137 тирәсе) [9, б.96].

Төркестанда хатын-кызлар мәгарифен дә татар педагогларының эшчәнлегеннән аерып карау мөмкин түгел. Бу мәсьәлә Т.Ә. Биктимирова хезмәтләрендә чагылыш таба [9]. Соңгы вакытларда татар хатын-кызларының Төркестанда мәгърифәтчелек эшчәнлеген яктырткан тикшеренүләр Урта Азия, аерым алганда үзбәк, галимнәре арасында да күренә башлады. Д. Насретдинованың диссертация эше татар һәм башкорт хатын-кызларының Төркестанда алып барган мәдәни-агарту эшләренә багышланган [23].

Мәктәпләр ачу, укыту белән беррәттән, аларның матди ягын кайгырту мәсьәләсен дә татарлар үзләре хәл иткән. Әйтик, Верный (хәзерге Алматы) шәһәрендә ачылган кызлар мәктәбенең попечителе Вятка губернасы татары З. Таҗетдинов, укытучылары Уфа мәдрәсәләрен тәмамлап шул якларга килгән М. Якупова һәм М. Сәгъдиева булса, мәктәпкә матди ярдәмне даими рәвештә татар сәүдәгәре Х. Габделвәлиев һәм аның уллары күрсәткән [9, б.97].

Кызлар мәктәпләрендә, татарлар белән беррәттән, башка милләт вәкилләре дә белем алган. Пишкек шәһәрендәге кызлар җәдит мәктәбендә, мәсәлән, 1912–1913 елларда укыган 70 кызның 50се – татар, 20се кыргыз кызы була. Аларга Казан һәм Уфада кызлар мәдрәсәләрен тәмамлаган татар кызлары белем биргән. Укыту ирләр мәктәпләре программасы нигезендә алып барылган, өстәмә рәвештә кул эшләре дәресләре үткәрелгән [14, б.44]. 1903 елдан башлап татар мөгаллимәләре кызлар өчен ачылган рус – җирле халык мәктәпләрендә дә укытканнар [23, б.3].

Татар хатын-кыз мәгърифәтчеләренең Төркестандагы эшчәнлеге, беренче чиратта, аларның хатын-кыз мәгарифенә юл ачулары белән билгеләнсә, икенчедән, шул милләт хатын-кызлары арасыннан милли кадрлар әзерләүгә һәм милли мәктәпләр оештыруга булышлык итүләреннән гыйбарәт. Мәсәлән, Коканд шәһәрендәге Галчасай мәхәлләсендә 1913 елда татар хатын-кыз педагоглары йогынтысында Мөхәммәтҗан Холикий ачкан яңа ысуллы кызлар мәктәбендә аның туганы Салияхон Абдулхалик кызының да укытуы билгеле [23, б.15].

Татар җәдит мәктәпләренә нигез салган һәм анда эшләгән шәхесләргә килгәндә, шактый дәрәҗәле, татарлар арасында гына түгел, Төркестанда да яхшы билгеле булган исемнәрне атарга мөмкин. Мәсәлән, Ташкенттагы И. Гаспринский исемендәге татар җәдит мәктәбенә Әбүбәкер Диваев, Габдулла Биги, Булат Сәлиев, Габдрахман Чанышевлар нигез сала [5, б.400]. Ә татарның билгеле химаячеләре бертуган Хөсәеновларның, Эрбет, Мәкәрҗә ярминкәләрендә генә түгел, шулай ук Сәмәрканд, Коканд шәһәрләрендә һәм хәтта ислам дине үзәге Мәккәдә дә мәчет һәм җәдит мәдрәсәләре ачулары турында мәгълүматлар бар.

Баштагы чорда татарларның казахларга аң-белем таратуында Казах далаларының Россия Империясенә кушылуына булышлык итү чарасын күргән хөкүмәт XIX гасырның икенче яртысында бу ике милләтнең үзара тәэсир итешүенә борчылуын белдерә. Бигрәк тә казахларның да, татарлар кебек үк, һәр торак урында мәчет булуын теләүләре; алар арасында да Россиягә каршы фикерле аерым интеллигенция вәкилләре барлыкка килә башлау куркуга сала [20, б.48]. Ислам дине таралу һәм ныклап урнашу русларга карата тискәре мөнәсәбәт тудыру, алардан аерылу (ягъни руслаштыруга каршылык тудыру) һәм төрки халыкларның үзара берләшү чарасы буларак карала башлый. Татар муллаларының эшчәнлеге кысрыклана, аларга казахлар арасында никах һәм гаилә эшләрен хәл итү тыела, муллаларны казахларның үз араларыннан гына сайлап кую мөмкинлеге татар муллаларының даладан күпләп китүләренә сәбәп була [20, б.49–50]. Шулай итеп, татарларның беренче чорда хөкүмәт тарафыннан яклау тапкан мәгърифәтчелек эшчәнлеге XX гасыр башында пантюркизм һәм панисламизм идеяләрен тарату куркынычы күзлегеннән чыгып карала башлый. Җәдит мәктәпләренең Төркестан һәм Казах далалары халкын руслаштыру, чукындыру сәясәтен тормышка ашыру максатыннан ачылган рус – җирле халык мәктәпләре белән чагыштырганда көчәюе татарлар тәэсиренең артуына китерә торган зур көч буларак кабул ителә. Шул сәбәпле төрки халыкларның берләшүеннән, исламның өстенлек итүче дини идеологиягә әверелүеннән курыккан хөкүмәт Идел буе татарларының Төркестандагы һәм Казах далаларындагы эшчәнлегенә тоткарлык күрсәтү юлларын эзли. Мәсәлән, Акмолинск өлкәсе губернаторы татар муллаларын дала халкына белем бирүдән тыю, рус теле укытылмаган барлык татар мәктәпләрен ябу һәм аларның эшчәнлеген тикшереп тору, мөмкин булган кадәр казахлар өчен татар алфавитын рус язуы белән алыштыру кебек эш-гамәлләрне тәкъдим итә [20, б.48–49]. 1910 елда оештырылган «Татар-мөселман тәэсиренә каршы тору өчен махсус оешма» да («Особое совещание для выработки мер по противодействию татаро-мусульманскому влиянию») үз алдына әлеге максатларны куя. Бу планны тормышка ашыру юлындагы чараларның берсе – татарларның Төркестан мәктәпләрендә укытуларын тыюга юнәлдерелгән карар була. «Тәрҗеман» газетасының 1912 елның 20 апрель саны, «Вакыт» газетасына таянып, Төркестан администрациясенең «яңа ысуллы һәм кадими мәктәпләрдә бары тик анда укучылар кавеменә караган укытучылар гына эшли ала. Сарт – кыргызларны, ә татар сартларны укыта алмый», – дигән карарын җиткерә. Бу кагыйдәләр 1 июльдән тормышка ашырылырга, ә аны үтәмәгән мәктәпләр ябылырга тиеш булалар [33]. Әмма, Н. Бобровников билгеләвенчә, «сарт укытучылары аз әзерлекле, һәм, җирле укытучыларның фикеренчә, алар бары тик татар мөгаллимнәрен механик рәвештә кабатлыйлар; шул ук вакытта, икенче яктан караганда, бу чара сарт телендә дәреслекләр әзерләүгә этәрде, ә монысы, һичшиксез, зур әһәмияткә ия» [11, б.80]. Ә аң-белемгә, милләтне күтәрергә чакырган татар китап-

лары (мәсәлән, М. Гафури һ.б.) Төркестан халыкларына белем бирүдә тыелган китаплар исемлегенә кертелә [15, б.113].

«Инородческое обозрение» журналының 1913 елгы март санында басылган «Рус мөселманнары» дигән мәкаләдә бу уңайдан Эчке эшләр министры урынбасары А.Н. Харузинның фикере китерелә. Ул төрки халыкларның бер-берләренә тәэсире артуга куркуын белдерә. Аның татарларны кыргыз мәктәпләренә билгеләүгә каршы булуы да шуның белән билгеләнә [30, б.132].

Мәсьәлә шул заман татар газеталарында шактый киң чагылыш таба. Мәсәлән, «Йолдыз» газетасы, бу хакта борчылуын белдереп, «Төркестанның кайсы шәһәрендә, мәсәлән, Кокандта, нугай (татар. – *Л.М.*) мөгаллимнәре тарафыннан ачылган мәктәпләрне яптылар. Мөгаллиме сарт булган мәктәпләрнең ябылганы хәзергә мәгълүм түгелдер», – дип яза [39]. Шул ук вакытта мәкалә авторы «әгәр татар мәктәпләре генә ябылса, халык моңа әллә ни борчылмас, чөнки Казан татарларын Төркестанда һәр эштә искедән бирле кысынкылыклыйлар. Нугай мәктәпләре ябылу илә Төркестанда ысулы җәдидә бетмәс. Чөнки хәзер сартларның үз араларында да мөгаллимнәр күптер», – дип, татарлар башлап җибәргән җәдит мәктәпләренең эше дәвам итәчәккә ышану белдерә. Әлеге ышанычның икенче бер сәбәбе – бу чорда әле Төркестанда бу мәктәпләрне тикшерерлек, аларда укытуның торышына нәтиҗә ясый алырлык, җирле халыкларның телләрен һәм мөселман язуын белгән бер генә халык мәктәпләре инспекторының да булмавы белән бәйле. Шуңа күрә татарлар әлеге кагыйдәләрнең кәгазьдә генә калачагына шик белдермиләр [11, б.62]. Шулай итеп, хөкүмәт карары дөнья күргәннән соң да татарлар Төркестан мәктәпләрендә эшләүләрен дәвам итәләр, бу мәктәпләрдә татар балалары белән беррәттән башка милләт вәкилләре дә укый (Әйтик, Верный шәһәрендәге кызлар мәктәбендә 1913 елда татарлар белән беррәттән тагын 9 кыргыз һәм 9 үзбәк кызы белем ала [9, б.97]). Төркестан генерал-губернаторына урыннардагы жандарм идарәсе бүлекләреннән җиткерелгән хәбәрләрдә, кагыйдәләр чыкканнан соң да, берничә ел дәвамында Сырдәрья һәм шул тирәләрдәге өлкәләрдә җәен кыргызларны укыту өчен «Галия» мәдрәсәсендә укучы шәкертләрнең килүе, укытуның Казанда басылып чыккан дәреслекләргә нигезләнеп алып барылуы турында әйтелә [15, б.113].

Төрле милләт вәкилләре (татарлар, үзбәкләр, дунганнар, кашгарлылар, кыргызлар, казахлар һ. б.) белем алган мәктәпләрдә кулланылган дәреслекләр мәсьәләсе тагын бер үтә үзенчәлекле һәм кызыклы моментларның берсе. Билгеле булганча, татар теле – Төркестанда мәктәп, ягъни укыту теле булган. (Мисал өчен, 1902 елда Пишпекта ачылган татар мәчете каршындагы мәдрәсәнең бар бүлекләрендә дә укыту татар телендә алып барылган [1, б.40–41]). Әле җирле халык телләрендә дәреслекләрнең һәм аларны язарлык әзерлекле педагогларның бөтенләй булмавын искә алсак, шул чорда Идел буе мәктәпләрендәге дәреслекләрнең кулланылуы бернинди дә сорау тудырмый. Шулай итеп, Төркестан мәктәпләрендә татар авторларының дәреслекләре – Әхмәтһади Максуди әлифбалары

(«Мөгаллим әүвәл», «Мөгаллим сани яки әлифба гарәби») [18; 19], Риза Фәхретдин хрестоматияләре («Тәрбияле бала»), Хәбибрахман Зәбиринең «Рәһбәре сыйбиян», Харис Фәйзи-Чистапулиның «Ысулы җәгърәфия» [13; 35; 36] китаплары кулланылган. Шәригать кануннары Әхмәтһади Максудиның «Гыйбадәте исламия», «Гакаиде исламия» [17] дәреслекләре буенча алып барылган.

Укыту теле булудан тыш, татар теле рәсми документлар теле дә булып хезмәт иткән. «Экбаль» мәдрәсәсен тәмамлаучыларга, мәсәлән, татар телендә тутырылган шәһадәтнамәләр (дипломнар) бирелүе билгеле [12, б.22].

Шул ук вакытта 1910 еллардан соң, мәктәпләрне җирле халыклар телендә язылган дәреслекләр белән тәэмин итү ихтыяҗы туу белән, татар педагоглары һәм Казан типографияләренең роле тагын да арта. XX гасыр башында Казанда Төркестан халыкларының әдәби теле формалашуга, укуязуга өйрәтүгә ярдәм иткән дистәләрчә әдәби, фәнни-агарту характерындагы хезмәтләр басылып чыга [12, б.17]. XX гасырның 40 нчы елларына кадәр кыргыз телендә барлык дәреслек һәм башка уку әсбаплары Казанда һәм Уфада басыла. Шулай ук беренче кыргыз газеталары да озак вакытлар татар башкаласында чыга [4, б.79]. 1900–1917 еллар арасында казах фольклорына багышланган 307 китапның 259ы Казан типографияләрендә басылуы билгеле [16, б.109].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Казанда кыргыз мәктәпләре өчен дәреслекләр басыла. 1859 елда Казан университеты типографиясендә Оренбург генерал-губернаторы кушуы буенча Оренбург Чик буе комиссиясе каршындагы кыргыз (казах) мәктәбенең татар, рус, кыргыз телләре укытучысы, тылмач Мирсалих Бикчуринның «Начальное руководство к изучению арабского, персидского и татарского языков с кратким объяснением существующих в Оренбургском крае наречий башкир и киргизов с приложением к нему русско-персидско-татарских слов, разговоров и прописей» дигән кулланмасы [10] басылып чыга. Анда шәрекъ телләренең фонетикасы, лексикасы һәм грамматикасы буенча системалаштырылган мәгълүматлар бирелә, фольклор үрнәкләре һәм тематик сүзлекләр тәкъдим ителә. Бу китапның әһәмияте аның мәдрәсәләрдә укытылган төп телләр – гарәп, фарсы телләре белән беррәттән, татар һәм Төркестанда яшәүче халыкларның телләрен үзара чагыштырып, аларны тулырак күзалларга һәм өйрәнергә мөмкинлек тудыруында. Моннан тыш, XX гасыр башында Идел буе мәдрәсәләре укытучыларының дәреслекләре (билгеле булганча, мөгаллимнәр, хәтта шәкертләр дә дәреслекләр язу белән шөгыльләнгән), башка төрки телләргә тәрҗемә ителеп, Төркестан мәктәп-мәдрәсәләренә җибәрелгән. Шундый педагогларның берсе – «Галия», «Хөсәения» мәдрәсәләрендә табигать фәннәре укытучысы, дәреслекләр авторы Габдулла Шнаси. Аның химия, физика һәм аерып предметларны укыту методикасына караган дәреслекләре казах, үзбәк, таҗик, башкорт телләренә тәрҗемә ителә һәм озак еллар дәвамында Россия халыкларына белем бирүдә файдаланыла [22, б.123]. Тагын бер татар мәгърифәтчесе – Сәйфелгабит Мәҗитов, 1925 елда каракалпак халкына әлифба һәм уку китаплары төзеп

биргән күренекле педагог буларак билгеле. Чыгышы белән Казан губернасы Үртәм авылыннан булган [6, б.440], гаиләсе белән Төркестан якларына барып ирешкән С. Мәҗитовны бүгенге көндә каракалпаклар үзләренеке саныйлар [34]. Совет чорында башка милли республикалар һәм кардәш халыклар мәгарифен үстерү өлкәсендә эшләгән татарларның саны, һичшиксез, бу гына түгел, алар биниһая күп. Ләкин әлеге мәкалә кысаларында аларның эшчәнлегенә тукталуны максат итмәдек. Бу турыда, нәтиҗә ясап, шуны гына әйтергә мөмкин: XX гасыр башында татар педагоглары башка милләтләр телендә дәреслекләр һәм газеталар чыгуны хуплыйлар, алай гына да түгел, методик яктан да, матди яктан да шактый зур ярдәм итәләр, тик, Н. Бобровников күрсәтүенчә, бер генә шарт куялар – башка төрки халыклардан аерылмаска һәм татар телен белергә [11, б.70].

Инде билгеле булганча, казах, кыргыз һ. б.төрки халыкларның атаклы шәхесләренең күбесе башлангыч белемне татар муллаларыннан алган. Казахларның Абае башта авыл мулласында, аннан соң Семипалатинск шәһәрендәге татар мәдрәсәсендә укыган. XIX–XX гасырларда Төркестан мәктәп-мәдрәсәләре өчен педагогик кадрлар әзерләүдә Идел буе татар мәдрәсәләренең ролен дә ассызыклап үтү мөһим. XX гасыр башында татарның иң алдынгы мәдрәсәләреннән берсе «Мөхәммәдия»дә, мәсәлән, Себер, Кавказ яшьләре белән бергә байтак Төркестан егетләре дә укый [5, б.418]. Татар мөгаллимнәрен Төркестаннан куа башлаганнан соң, хөкүмәтнең укытучыларның аерым кавемгә карарга тиешлекләре турындагы карарына җавап йөзеннән, «Галия» мәдрәсәсе кискен рәвештә татар булмаган шәкертләрне (казах, төрекмен, чиркәс, кыргыз һ.б.) кабул итүне бермә-бер арттырган. Биредә казах халкының бөек шәхесләре Мәгъҗан Жумабаев, Баимбәт Майлин һәм башкалар укый. 1906–1916 елларда «Галия»дә Урта Азиядән килгән 242 шәкерт белем ала [12, б.17]. Идел буе мәдрәсәләре кардәш халыклар өчен шактый санда язучы, шагыйрьләр, журналистлар, мәгариф һәм фән хезмәткәрләре һәм мәдәниятнең башка өлкәләрендә дан казанган шәхесләр тәрбияләүдә катнашкан. Мәсәлән, «Хөсәениядә» казах әдипләре һәм шагыйрьләре Б. Җумагалиев белән Ж. Теләпбиргәнов, беренче казах профессоры, галим Х. Җубанов белем алып чыкканнар; «Кызыл Үзбәкстан» газетасы редакторы Мирмөхсин Ширмөхәммәдовның – «Галия»дә, «Мәгариф вә укытучы», «Яшь көч» журналлары редакторы, язучы Шакир Сөләйманның «Хөсәения»дә белем алганлыгы билгеле [5, б.420].

Эстәрлебаш мәдрәсәсе дә кардәш халыкларга белем бирү үзәге булган. Анда татарлар һәм башкортлардан тыш, кыргызлар, казахлар һәм башка төрки халык вәкилләре укыган. Мәдрәсәдә мәҗбүри предметлар – гарәп һәм фарсы телләре – белән беррәттән татар һәм казах телләре дә укытылган. Биредә белем алган казах шәкерте Чокан Вәлиханов (1835–1863) мәгърифәтче, язучы һәм галим буларак дан казана. Мәдрәсәдә аеруча сәләтле дип табылган казах шәкертләрен казах балаларын укыту өчен шунда ук мөгаллимлеккә калдыру традициясе дә булган.

Татар мәдрәсәләрен тәмамлаган күп кенә татарларның Төркестанда педагоглык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләре билгеле (шагыйрь Ш. Бабич һ. б.). Эстәрлебаш мәдрәсәсен тәмамлаган татар шагыйре һәм мәгърифәтчесе Мифтахетдин Акмулла (1831–1895), мәсәлән, 25 яшендә казах далаларына китә һәм шунда балалар укыту белән шөгыльләнә. Казах акыннарының иҗаты белән яхшы таныш булган шагыйрь үзе дә казах телендә әсәрләр иҗат итә. Хәтта «Акмулла» тәхәллүсен дә үзләренең шул исемдәге акыннары вафат булганнан соң аңа казахлар биргән, дигән фикер бар [37, б.406, 411]. Туган теленнән тыш, башка төрки телне яхшы белгәнгә һәм шул телләрдә иҗат иткәнгә, Акмулланы татарлар гына түгел, башкортлар, казахлар, кыргызлар, нугайлар һ. б.үз шагыйре саныйлар.

Совет чорында татарларның кардәш төрки халыкларга мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре аерым өйрәнүне таләп итә. Шулай да бер-ике исемне күрсәтү кирәктер. Болар: «Иштирәкиюн» газетасын оештырган һәм аңа җитәкчелек иткән якташларыбыз Гариф Келиблиев һәм Әхмәт Донской, Ташкент шәһәрендәге Татар мәгариф институты ректоры Габдулла Мостакаев, «Бохара тарихын» язган профессор Булат Сәлиев, үзбәк әдәбияты буенча беренче дәреслекләр авторы, галим Габдрахман Сәгъди [5, б.402, 404, 430], телара сүзлекләр төзегән Сәхи Рәхмәтуллин һ. б.Кайберләре шул заманда ук тиешле бәясен ала, мәсәлән, Урта Азия шәһәрләрендә басмаханәләр оештырган, типография эшчеләре әзерләгән Шаһингәрәй Биккуловка 1918 елда, Төркестанда беренчеләрдән булып, «Хезмәт батыры» исеме бирелә [5, б.401]. Ләкин кардәш халыкларга аң-белем таратуга гомерләрен багышлаган күп санлы татар педагогларының, мәгърифәтчеләренең эшчәнлеге тирәнтен өйрәнүне көтә.

Шулай итеп, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар мәгърифәтчеләре Төркестан һәм Казах далалары халыклары арасында аң-белем, мәгърифәт таратуда шактый зур роль уйнаганнар. Аларның җәдит мәктәпләре аша дөньяви белем бирү нигезләрен урнаштыру, әлеге халыклар телләрендә укыту-методик әдәбият булдыру һәм милли педагогик кадрлар әзерләүгә юнәлдерелгән эшчәнлекләре Урта Азия һәм Казахстанда яшәүче халыкларның милли мәгариф системасы барлыкка килүгә ярдәм итте.

## ӘДӘБИЯТ

1. Айтмамбетов Д. Дореволюционные школы в Киргизии. Фрунзе: Изд-во АН Киргизской ССР, 1961. 128 с.

2. Айтматов И.Т. О роли татарских женщин в формировании кыргызской интеллигенции в 20–30 гг. XX века // Татары в истории Киргизии. Прошлое и современность: материалы Международной научно-практической конференции. Бишкек: Изд-во КРСУ, 2010. С. 13–16.

3. Айтмухамбетов А.А. Народное образование и формирование казахской интеллигенции Северо-Западного Казахстана во второй половине XIX – начале XX века: автореф. дис. ... канд. ист. наук. Омск, 2000. 30 с.

4. Акчурин В.А. Вечные странники // Татары в истории Киргизии. Прошлое и соременность. Бишкек: Изд-во КРСУ, 2010. С. 75–89.

5. Әйди Т. Тылсымлы көч // Әйди Т. Сайланма әсәрләр. Дүрт томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Т. 3. Б. 396–427.

6. Әйди Т. Гомерлек мәхәббәт // Әйди Т. Сайланма әсәрләр. Дүрт томда. Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. Т. 3. Б. 440–448.

7. Бартольд В.В. История турецко-монгольских народов. Ташкент: Казах. Высш. пед. институт, 1928. 35 с.

8. Бартольд В.В. История культурной жизни Туркестана. Л.: Изд-во Академии наук СССР, 1927. 256 с.

9. Биктимирова Т. Ил язмышын салып иңнәренә. Казан: Алма-Лит, 2006. 239 б.

10. Бекчурин М. Начальное руководство к изучению арабского, персидского и татарского языков с кратким объяснением существующих в Оренбургском крае наречий башкир и киргизов с приложением к нему русско-персидско-татарских слов, разговоров и прописей. Казан: Тип. Казан. ун-та, 1859. 128 с.

11. Бобровников Н.А. Русско-туземные училища, мектебы и медресы Средней Азии: путевые заметки. С.-Пб.: Сенатская тип., 1913. 90 с.

12. Галимова А.Р. Литературные связи киргизской и татарской поэзии конца XIX – первой половины XX в. Бишкек: Изд-во КРСУ, 2015. 142 с.

13. Зәбири Х. Рәһбәр сыйбиян. 1 нче кыйсем. Казан: Әхмәдуллиннар, 1904. 34 б.

14. Иманкулов М. К. Развитие системы образования в начале XX в. // Известия Кыргызской академии образования. 2016. № 1 (37). С. 42–46.

15. Карлыбаев М.А. «Татарские» книги в мектебах Каракалпакии в начале XX века // Тюркоязычная книга: наследие веков. Казань: ИЯЛИ, 2012. С. 112–114.

16. Кеменгер К.Р. Роль и значение книгопечатных издательств Казани в духовной жизни казахского народа // Тюркоязычная книга: наследие веков. Казань: ИЯЛИ, 2012. С. 105–112.

17. Максуди Ә. Гыйбадәте исламия. Казан: Тип. Домбровкого, 1898. 112 б.

18. Максуди Ә. Мөгаллим әүвәл. Казан: Ун-т матб., 1892. 142 б.

19. Максуди Ә. Мөгаллим сани яки әлифба гарәби. Казан: Харитонов матб., 1904. 40 б.

20. Махмутов З.А. Татары Петропавловска и Северо-Казахстанской области: история и этнические процессы. Казань: Яз, 2015. 156 с.

21. Мортазина Л.Р. Татар педагогик фикерен өйрәнүнең теоретик һәм методологик нигезләре («Татар педагогик фикере антологиясе»н төзү тәҗрибәсе нигезендә) // TATARICA. 2014. № 1 (2). Б. 209–222.

22. Муртазина Л.Р. Научно-педагогическая деятельность Габдуллы Сабировича Шнаси (1885–1938) // Вестник Томского государственного педагогического университета. 2016. № 8. С. 121–124.

23. Насретдинова Д.М.Туркистоннинг маданий ҳаётида татар-бошқирд аёлларининг тутган ўрни (XIX аср охири – XX асрнинг биринчи чораги): тарих ф. канд. дис. автореф. Тошкент, 2011. 29 б.

24. Павлович М.П. Культурные достижения тюрко-татарских народностей со времен Октябрьской революции // Новый Восток. 1926. № 12. С. 6–7.

25. Пашино П.И. Туркестанский край в 1866 году: Путевые заметки П.И. Пашино. М.: Типография Тиблена и К° (Неклюдова), 1868. 176 с.

26. Плоских В.М. Роль татар в становлении киргизско-российских отношений // Татары в истории Киргизии. Прошлое и современность: материалы Международной научно-практической конференции. Бишкек: Изд-во КРСУ, 2010. С. 16–44.

27. Приходов М. Киргизы-мусульмане // Инородческое обозрение. Приложение к журналу «Православный собеседник» за март 1913 года. Кн. 2-я. Казань: Центр. Тип., 1913. С. 83–112.

28. Расулов А.Н. Интернациональная помощь партийных организаций, трудящихся Средневолжского региона народам Туркестана (1918–1924 гг.). Казань, 1990. 18 с.

29. Расулов А.Н. История взаимоотношений народов Туркестана, Поволжья и Приуралья (1917–1924): автореф. дис. … докт. ист. наук. Ташкент, 2005. 54 с.

30. Русские мусульмане // Инородческое обозрение. Приложение к журналу «Православный собеседник» за март 1913 года. Кн. 2-я. Казань: Центр. тип., 1913. С. 131–133.

31. Сәмәрканд мәктәбе (идарәия мәктүбләрдән) // Тәрҗеман. 1893. 7 ноябрь.

32. Татар педагогик фикере антологиясе. 2 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Т. 1. 407 б.

33. Төркестан мәктәпләренә даир // Тәрҗеман.1912. 20 апрель.

34. Уразбаева Р. Духовное образование в Каракалпакстане и формирование интеллектуальной и политичекой элиты (конец XIX – первая треть XX века). URL: http://ia-centr.ru/expert/2319/ (дата обращения 20.03.2017).

35. Фәйзи-Чистапули Х. Ысулы җәгърәфия. Казан: Борадәран Кәримовлар, 1900. 250 б.

36. Фәхретдин Р. Тәрбияле бала: Беренче сыйныф шәкертләре өчен. Казан: Милләт, 1887. 16 б.

37. Фәхреддин Р. Асар. 3һәм 4 томнар. Казан: Рухият, 2010. 648 б.

38. Хафизов Г. Г.Культуртрегерскаядеятельность татарской интеллигенций в XIX – первой четверти XX вв. Казань: Изд-во Казанского гос. ун-та, 2003. 283 с.

39. Ысулы җәдидә // Йолдыз. 1911. 11 гыйнвар. № 631.

**Автор турында белешмә:** Мортазина Ляля Рәис кызы – педагогика фәннәре кандидаты, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, ТР ФА Ш. Мәрҗәни исемендәге Тарих институты (420111, Батурин урамы, 7, Казан, Российская Федерация); lyalyamur@mail.ru

# ПРОСВЕТИТЕЛЬСКАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ ТАТАР В ТУРКЕСТАНЕ И КАЗАХСКИХ СТЕПЯХ В КОНЦЕ XIX – НАЧАЛЕ XX ВВ.

***Л.Р. Муртазина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*lyalyamur@mail.ru*

В статье освещается просветительская деятельность татар в Туркестане и Казахских степях в конце XIX – начале XX вв. Уделяется внимание роли татар в распространении мусульманских традиций и обычаев в степи, мусульманской культуры среди родственных народов. Описывается негативное отношение пра-

вительства к этому вопросу, также его освещение в татарской периодической печати начала XX в. и в трудах русских исследователей. Анализируется деятельность татарских педагогов по открытию в Туркестане и Казахских степях мектебов и медресе, в том числе и джадидских, обучению татар и других тюркских народов края, обеспечению учебно-методической литературой и подготовке педагогических кадров из среды местного населения.

**Ключевые слова:** Туркестан, просвещение, образование, родственные языки, мугаллим, татарские педагоги, медресе, русско-туземная школа, джадидская школа, школа для девочек, новый метод, учебник, букварь

**Сведения об авторе:** Муртазина Ляля Раисовна – кандидат педагогических наук, ведущий научный сотрудник, Центр истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш.Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7, Казань, Российская Федерация); lyalyamur@mail.ru

## EDUCATIONAL ACTIVITY OF TATARS IN TURKESTAN AND KAZAKH STEPPES IN LATE 19th – EARLY 20th CENTURY

***L.R. Murtazina***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*lyalyamur@mail.ru*

Educational activity of Tatars in Turkestan and the Kazakh steppes in the late 19th – the early 20th century is considered in the article. Special attention is given to the role of Tatars as distributors of Muslim traditions and customs in the steppe, Muslim culture among the related peoples. The paper touches upon theissue of of the government's negative attitude towards Tatars who were seen as Muslim missionaries. The author traces illumination of this problem in the Tatar periodicals of the early 20th century and works of Russian researchers. The work of Tatar teacherson opening mektebs and madrasahs, including jadidi schools, in Turkestan and the Kazakh steppes is analyzed. The article focuses on their activities aimed ateducating Tatars and other Turkic peoples, providing schools with textbooks written by Tatar authors, the attention to the role of Tatars in training teaching staff from the local population.

**Keywords:** abc-book, dzhadidsky school, education, madrasah, mullah, mugally, new method, Tatar teachers, Russian-native school, related languages, school for girls, textbook, Turkestan

REFERENCES

1. Aytmambetov D. *Dorevolyutsionnye shkoly v Kirgizii* [Pre-revolutionary Schools in Kyrgyzstan]. Frunze, Academy of Sciences of the Kirghiz SSR Publ., 1961. 128 p. (In Russian)

2. Ajtmatov I.T. O roli tatarskih zhenshhin v formirovanii kyrgyzskoj intelligencii v 20–30 gg. XX veka [On the Role of Tatar Women in Formation of the Kyrgyz Intellectuals in the 20–30's of the 20th Century]. *Tatary v istorii Kirgizii. Proshloe i sovremennost':* Materialy Mezhdunarodnoj nauchno-prakticheskoj konferencii [Tatars in the History of Kyrgyzstan. Past and Present: Proceedings of the International Scientific-Practical Conference]. Bishkek, Kyrgyz-Russian Slavic UniversityPubl., 2010, pp. 13–16. (In Russian)

3. Aytmukhambetov A.A. *Narodnoe obrazovanie i formirovanie kazakhskoy intelligentsii Severo-Zapadnogo Kazakhstana vo vtoroy polovine XIX – nachale XX veka. Avtoref. dis. ... kand. ist. nauk.* [National Education and Formation of the Kazakh Intellectuals of Northwest Kazakhstan in the Second half of 19th – the Beginning of the 20th Century. Abstract of Candidate Historical Sciences Diss]. Omsk, 2000. 30 p. (In Russian)

4. Akchurin V.A. Vechnye stranniki [Eternal Wanderers]. *Tatary v istorii Kirgizii. Proshloe i soremennost'* [Tatars in the History of Kyrgyzstan. The Past and the Present]. Bishkek, Kyrgyz-Russian Slavic University Publ., 2010.pp. 75–89. (In Russian)

5. Äjdi T. Tylsymly köch [Magic Power]. *Äjdi T.Sajlanma äsärlär* [Aidi T. Selected Works]. In 4 volumes. vol. 3. Kazan, Tatar Book Publ. House, 2015, pp. 396–427. (In Tatar)

6. Äjdi T. Gomerlek mähäbbät [Eternal Love]. Äjdi T. *Sajlanma äsärlär.* [Aidi T. Selected Works]. In 4 volumes. Kazan, Kazan, Tatar Book Publ. House, 2015, pp. 440–448. (In Tatar)

7. Bartol'd V.V. *Istorija turecko-mongol'skih narodov* [History of the Turkish-Mongolian Peoples]. Tashkent, Kazakh Executive Pedagogical InstitutePubl., 1928. 35 p. (In Russian)

8. Bartol'd V.V. *Istoriya kul'turnoy zhizni Turkestana* [The History of the Cultural Life of Turkestan.]. Leningrad, Academy of Sciences of the USSR Publ., 1927. 256 p. (In Russian)

9. Biktimirova T. *Il yazmyshyn salyp iñnärenä* [The Fate of the Country on Brittle Shoulders]. Kazan, «Alma-Lit» Publ., 2006. 239 p. (In Tatar)

10. Bekchurin M. *Nachal'noe rukovodstvo k izucheniju arabskogo, persidskogo i tatarskogo jazykov s kratkim objasneniem sushhestvujushhih v Orenburgskom krae narechij bashkir i kirgizov s prilozheniem k nemu russko-persidsko-tatarskih slov, razgovorov i propisej* [The Initial Instructionfor Studying Arabic, Persian, and Tatar Languages With a Short Explanation of the Adverbs Existing in the Orenburg Region dialects of the Bashkir and Kyrgyz With an Appendix of the Russian-Persian-Tatar Words, Conversations and Copy-books]. Kazan, Kazan Univ.Publ., 1859. 128 p. (In Russian)

11. Bobrovnikov N.A. *Russko-tuzemnye uchilishcha, mekteby i medresy Sredney Azii: putevye zametki* [Russian-native Schools, Mektebas and Madrassas of Central Asia: Traveling Notes]. Saint Petersburg, Senatskaya Publ., 1913. 90 p. (In Russian)

12. Galimova A.R. *Literaturnye svyazi kirgizskoy i tatarskoy poezii kontsa XIX – pervoy poloviny XX v.* [Literary Relations of the Kyrgyz and Tatar Poetry of the late 19th – the First Half of the 20thCentury]. Bishkek, Kyrgyz-Russian Slavic University Publ., 2015. 142 p. (In Russian)

13. Zäbiri H. *Rähbär syjbijan* [Guide of Children]. 1 part. Kazan, Ähmädullinnar Publ., 1904. 34 p. (In Tatar)

14. Imankulov M.K. Razvitie sistemy obrazovaniya v nachale XX veka [The Development of the Education System in the Early Twentieth Century]. *Izvestiya Kyrgyzskoy Akademii obrazovaniya – Proceedings of the Kyrgyz Academy of Education.* 2016. no. 1 (37), pp. 42–46. (In Russian)

15. Karlybaev M.A. «Tatarskie» knigi v mektebah Karakalpakii v nachale 20 veka [The "Tatar" Books in Schools of Karakalpakstan at the early 20th Century]. *Tjurkojazychnaja kniga: nasledie vekov* [Türkic-Speaking Book: a Legacy of Centuries]. Kazan, Institute of Language, Literature and History, 2012, pp. 112–114. (In Russian)

16. Kemenger K.R. Rol' i znachenie knigopechatnyh izdatel'stv Kazani v duhovnoj zhizni kazahskogo naroda [The Role and Value of Book Publishing Houses of Kazan in Spiritual Life of the Kazakh People] *Tjurkojazychnaja kniga: nasledie vekov*[Türkic-speaking book: a Legacy of Centuries]. Kazan, Institute of Language, Literature and History, 2012, pp. 105–112. (In Russian)

17. Maksudi Ä. *Gyjbadäte islamija* [Muslim Prayer]. Kazan, Dombrovkogo Publ., 1898. 112 p. (In Tatar)

18. Maksudi Ä. *Mögallim äüväl* [The First Teacher]. Kazan, Univ. Publ., 1892. 142 p. (In Tatar)

19. Maksudi Ä. *Mögallim sani jaki älifba garäbi* [The Second Teacher or Arabic Alphabet Book]. Kazan, Haritonov Publ., 1904. 40 p. (In Tatar)

20. Mahmutov Z.A. *Tatary Petropavlovska i Severo-Kazahstanskoj oblasti: istorija i jetnicheskie processy* [The Tatars of Petropavlovsk and North Kazakhstan Area: History and Ethnic Processes]. Kazan, Yaz Publ., 2015. 156 p. (In Russian)

21. Murtazina L.R. Tatar pedagogik fikeren öyränünen teoretik häm metodologik nigezläre [The Theoretic and Methodological Foundation of Studying Tatar Pedagogical Thought (On the Experiment of Compiling an Antology of Tatar Pedagogical Thought)]. *TATARICA*. 2014, no. 1(2), pp. 209–222. (In Tatar)

22. Murtazina L.R. Nauchno-pedagogicheskaya deyatel'nost' Gabdully Sabirovicha Shnasi (1885–1938) [The Research and Pedagogical Work of Gabdulla Sabirovich Schnasi (1885–1938)]. *Vestnik Tomskogo gosudarstvennogo pedagogicheskogo universiteta – Bulletin of the Tomsk State Pedagogical University.* 2016, no. 8, pp. 121–124. (In Russian)

23. Nasretdinova D.M. *Turkistonning madaniy xaetida tatar-boshkird aellarining tutgan ӯrni (XIX asr okhiri – XX asrning birinchi choragi).Tarikh f. diss. avtoref* [The Role of Tatar-Bashkir Women in the Cultural Life of Turkistan (the late 19th – the first quarter of the 20th Centuries. Abstract of Candidate Historical Sciences Diss.]. Tashkent, 2011. 29 p. (In Uzbek)

24. Pavlovich M.P. Kul'turnye dostizhenija tjurko-tatarskih narodnostej so vremen Oktjabr'skoj revoljucii [The Cultural Achievements of the Turkic-Tatar Peoples Since the Time of the October Revolution]. *Novyj Vostok – New East.* 1926, no. 12, pp. 6–7. (In Russian)

25. Pashino P.I. *Turkestanskij kraj v 1866 godu: Putevye zametki P.I. Pashino* [Turkestan in 1866: Travel Notes of Pashino P.I.]. Moscow, Tiblena i K° (Nekljudova) Publ., 1868. 176 p. (In Russian)

26. Ploskih V.M. Rol' tatar v stanovlenii kirgizsko-rossijskih otnoshenij [Role of Tatars in Formation of the Kyrgyz-Russian Relations]. *Tatary v istorii Kirgizii. Proshloe i sovremennost': Materialy Mezhdunarodnoj nauchno-prakticheskoj konferencii* [Tatars in the History of Kyrgyzstan. The Past and the Present: Proceedings of the

International Scientific-Practical Conference]. Bishkek, Kyrgyz-Russian Slavic University Publ., 2010, pp. 16–44. (In Russian)

27. Prikhodov M. Kirgizy-musul'mane [Muslim Kirghiz]. *Inorodcheskoe obozrenie. Prilozhenie k zhurnalu «Pravoslavnyy sobesednik» za mart 1913 goda* [Foreign Review. Supplement to the Magazine "Orthodox Interlocutor" for March 1913]. The 2nd book. Kazan, Central Printing House, 1913, pp. 83–112. (In Russian)

28. Rasulov A.N. *Internacional'naja pomoshh' partijnyh organizacij, trudjashhihsja Srednevolzhskogo regiona narodam Turkestana (1918–1924 gg.)* [International Help of the Party Organizations, Workers of the Middle Volga Region to the People of Turkestan (1918–1924)]. Kazan, 1990. 18 p. (In Russian)

29. Rasulov A.N. *Istoriya vzaimootnosheniy narodov Turkestana, Povolzh'ya i Priural'ya (1917–1924).Avtoref. diss. ... d.i.n.* [The History of Relations Betweenthe Peoples of Turkestan, the Volga Region, and the Ural Provinces (1917 – 1924). Abstract of Candidate Historical Sciences Diss.]. Tashkent, 2005. 54 p. (In Russian)

30. Russkie musul'mane [Russian Muslims]. *Inorodcheskoe obozrenie. Prilozhenie k zhurnalu «Pravoslavnyy sobesednik» za mart 1913 goda* [Foreign Review. Supplement to the Magazine "Orthodox interlocutor" for March 1913]. 2 book. Kazan, Central Printing house, 1913, pp. 131–133. (In Russian)

31. Sämärkand mäktäbe (idaräija mäktüblärdän) [Samarkand. From letters to the editorial office]. *Tärceiman.* 1893. 7 nojabr (In Tatar)

32. *Tatar pedagogik fikere antologiyase* [The Antology of Tatar Pedagogical Thought]vol.1. Ed. By F.M.Soltanov, M.M.Gibatdinov, L.R.Mortazina. Kazan, Kazan, Tatar Book Publ. House, 2014. 407 p. (In Tatar)

33. *Törkestan mäktäplärenä dair* [Rules about Muslim schools ]. *Tärceman*. 1912. 20 aprel (In Tatar)

34. Urazbaeva R. *Duhovnoe obrazovan ie v Karakalraktane i formirovanie intellektual'noj i politichekoj jelity (konec XIX – pervaja tret' XX veka)* [Spiritual Education in Karakalpakstan and Formation of Intellectual and Political Elite (of the late 19th – the First Third of the 20th Century)] (in Russian) Available at: http://ia-centr.ru/expert/2319/ (accessed 20.03.2017)

35. Fäjzi-Chistapuli H. *Ysuly cägräfija* [Geography]. Kazan, Boradaeran Kärimovlar Publ., 1900. 250 p. (In Tatar)

36. Fähretdin R. *Tärbijäle bala.* Berenche syjnyf shäkertläre öchen [Well-mannered Child]. Kazan, 1889. 16 p. (In Tatar)

37. Fäkhreddin R. *Asar.* 3 häm 4 tomnar. Kazan, Rukhiyat Publ., 2010. 648 p. (In Tatar)

38. Khafizov G.G. *Kul'turtregerskaya deyatel'nost' tatarskoy intelligentsiy v XIX – pervoy chetverti XX vv.* [Kulturtregerskih Activities of the Tatar Intelligentsia in the 19th – the First Quarter of 20th Centuries]. Kazan, Kazan State Univ. Publ., 2003. 283 p. (In Russian)

39. Ysuly cädidä [Dzhadid Method]. *Yoldyz – Star.* 1911. 11 yanvar. no 631 (In Tatar)

**About the author:** Lyalya R. Murtazina is a Candidate of Science (Pedagogy), Leading Research Fellow, the Center of History and Theory of National Education, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7, Baturin Str., Kazan 420111, Russian Federation); lyalyamur@mail.ru